МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 30/о

«25» 02 2021

БОЕРЫК

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында» 2017 елның 01 февралендәге 17/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына

кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2017 елның 01 февралендәге 17/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 11 октябрендәге 180/о номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 107/о номерлы, 2019 елның 21 августындагы 106/о номерлы, 2020 елның 23 ноябрендәге 191/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә үзгәреш кертеп, кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында конкурс комиссиясендә өч елдан артык булган бәйсез эксперт үз вәкаләтләрен 2021 елның 30 июненә кадәр саклый дип билгеләргә.

3. Юридик бүлек җитәкчесе Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Отдел межрегиональных связей и контроля исполнения документов

Министр М.М.Айзатуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 1 февралендәге 17/о номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 25 февралендәге 30/о номерлы боерыгы редакциясендә)

# Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – Конкурс) үткәрүнең тәртибен, шартларын һәм методикасын билгели.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә (алга таба – граждан хезмәте) тигез дәрәҗәдә үтеп керүенең конституциячел хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында (алга таба – Министрлык) Конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар хезмәтенә мәгълүмат технологияләрен кертүнең кайбер чаралары турында» 2018 елның 5 мартындагы 227 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127

номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә уздырыла.

Конкурс Министрлыкта граждан хезмәте вакант вазыйфасын (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасын) биләү өчен дәгъва белдерүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфага карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Конкурс үткәрелә торган максатлар:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә гражданнарның граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүендә конституциячел хокукларын, шулай ук граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар арасыннан сайлап алу;

Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.4. Конкурс үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

конкурс биремнәрен һәм процедураларны үтәгәндә барлык кандидатлар өчен тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны граждан хезмәте культурасына, һөнәри вәкаләтлелеккә һәм шәхси-эшлекле сыйфатларга туры килү критерийлары нигезендә бәяләү;

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) таләпләренә туры килә торган затларны конкурста катнашучылар арасыннан аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләрен чагыштыру юлы белән ачыклау.

1.5. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс граждан хезмәтенең, законнарга туры китереп, конкурс нигезендә биләргә мөмкин булган вакантлы вазыйфасы булган очракта, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

1.6. Конкурс үткәрү турында карар тиешле структур бүлекчә җитәкчесе яки дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан әзерләнгән хезмәт язуы нигезендә министр тарафыннан кабул ителә.

1.7. Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә карата конкурс дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан, Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү буенча белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗын һәм Министрлыктагы кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.8. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

«җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен билгеле бер чорда биләү өчен билгеләгәндә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә торган, «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендәге кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.9. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

## 2. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эш тәртибе

2.1. Конкурсны үткәрү өчен Министрлык боерыгы белән даими нигездә гамәл кылучы конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясенең составы Министрлык боерыгы белән раслана. Конкурс комиссиясенең объективлылыгын һәм эшенең бәйсезлеген арттыру максатларында министр карары нигезендә аның составы даими рәвештә (кагыйдә буларак ел саен) үзгәреп тора.

2.2. Конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегеннән һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырыла торган структур бүлекчәсеннән), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, бәйсез экспертлар – тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә кадр технологияләре һәм дәүләт граждан хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булып торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.

Министрлык карамагындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.3. Конкурс комиссиясенең рәисе аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырыш үткәрү көнен билгели, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга имза сала.

Конкурс комиссиясе рәисе булмый торган чорда аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары үти.

Конкурс комиссиясенең сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин

итә (гаризаларны терки, кабул итә, эшләрне формалаштыра, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен алып бара һ.б.).

2.4. Граждан хезмәтенең вазыйфаи вәкаләтләрен үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелгәндә конкурс комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.5. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге булмаслык рәвештә төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.7. Конкурс комиссиясе:

конкурсны үткәрү шартларын регламентлый торган документларны, аны үткәрү өчен кирәкле булган методик һәм бүтән материалларны раслый;

кандидатлар тарафыннан граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) тапшырылган документларны тикшергәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларның куелган таләпләргә туры килүен бәяли;

конкурска йомгак ясау, кандидатны конкурста җиңүче итеп тану турында карар кабул итә, аны Министрлыкның кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим итә.

2.8. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәл иткеч була. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән риза булмаган очракта, махсус фикерен белдерергә мөмкин, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясендәге әлеге әгъзаның имзасы белән беркетелә.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат юклыгында кабул ителә һәм аны граждан хезмәте вазыйфасына билгеләү (кадрлар резервына кертү) яисә моннан баш тарту өчен нигез булып тора.

2.10. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Аталган кандидатның ризалыгы белән, ул Министрлыкның кадрлар резервына кертелергә мөмкин.

2.11. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган

карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре), шушы Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына туры китереп, конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, анда рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары имза куя. Шул ук вакытта конкурс комиссиясе тарафыннан граждан хезмәте вазыйфасына беренче мәртәбә билгеләнә торган гражданин өчен сынау чорының озынлыгы буенча киңәшләр бирелергә мөмкин.

2.12. Конкурс оештыруны һәм үткәрүне, конкурс комиссиясе эшен дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тәэмин итә. Министрлыкта конкурсны оештыру «Дәүләт хезмәтенең һәм идарә кадрларының федераль порталы» дәүләт мәгълүмат ресурсыннан (алга таба – Дәүләт хезмәтенең һәм идарәи кадрларның федераль порталы) һәм «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Кадрларның бердәм мәгълүмат системасы) файдаланып гамәлгә ашырыла.

2.13. Конкурс комиссиясе тарафыннан утырышны аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме белән, мондый карар сәбәбен (нигезен) күрсәтеп, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында конкурс комиссиясе карары кабул ителергә мөмкин.

2.14. Министрлык тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашу өчен Министрлыкта дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча кандидатларга карата әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында каралган таләпләргә җавап бирә торган һәм, әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасына туры китереп, кирәкле документларны һәм материалларны билгеләнгән чорда тапшырган гражданнар (граждан хезмәткәрләре) кертелә. Министрлыкның Министрлыкта конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәрләренә министр исеменә гариза тапшыру да җитә. Бүтән дәүләт органында вазыйфалар биләүче, Министрлыкта конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәрләре Министрлыкка министр исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырылган, имзаланган һәм граждан хезмәткәрләре граждан хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган рәвештәге анкетаны, фотосын теркәп тапшыра.

3.2. Граждан (граждан хезмәткәре) ризалыгы белән, граждан (граждан хезмәткәре) биләп торуга граждан дәгъва белдерә торган граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрне куллануга бәйле булса, дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләргә аны рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Гражданинның министр исеменә тапшырылган белешмәләренең дөрес булу-булмавы тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә бирелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерүгә дучар ителә.

3.3. Конкурста катнашу өчен документлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – Министрлык сайты) һәм «Дәүләт хезмәте һәм идарәи кадрлар федераль порталы»нда аларның кабул ителүе турында игълан урнаштырылган көннән соңгы 21 календарь көне эчендә кандидатлар тарафыннан Министрлыкка шәхсән, почта аша җибәреп яисә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә тапшырыла. Электрон рәвештәге документлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тапшырыла.

3.4. Хөрмәткә лаек сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру хөрмәткә лаек сәбәпләргә бәйле булганда, аларны тапшыру вакытлары министр боерыгы нигезендә күчерелергә мөмкин.

## 4. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерияләре Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфаларына белдерелә торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

4.3. Кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасына туры китерелгән бәяләү методлары нигезендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары категорияләреннән һәм төркемнәреннән (аның буенча кадрлар резервы формалаштырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеменнән) чыгып гамәлгә ашырыла.

4.4. Министрлыкның конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләү методларын куллану һәм конкурс биремнәрен формалаштыру турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

4.5. Конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләрнең үрнәк исемлеге һәм кыскача эчтәлеге шушы Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында китерелде.

4.6. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.7. Нәтиҗәләр кандидатлар исемлегендәге балларның күләме рәвешендә

күрсәтелә.

4.8. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.9. Конкурсның беренче этабы Министрлык сайтында, Дәүләт хезмәтенең һәм идарә кадрларының федераль порталында конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турында мәгълүмат урнаштырылган көннән башлана һәм 21 көннән иртәрәк булмаган чорда тәмамлана.

Беренче этапта Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс үткәрелү турында мәгълүмат әзерли һәм Министрлык сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүматы системасында урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала:

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы;

әлеге вазыйфаны биләү өчен дәгъва белдерүчегә белдерелә торган квалификация таләпләре;

граждан хезмәтен узу шартлары;

конкурсны уздыруның бәяләү методлары турында белешмәләр;

дәүләт граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламенты;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының федераль порталында урнаштырылган беренчел тестка сылтама;

документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документлар кабул ителә торган срок, конкурс уздыруның күздә тотылган датасы, аны уздыру урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмат материаллары;

гражданин (граждан хезмәткәре) тапшырган документларны тикшерә. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә;

гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (башка төр дәүләт хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, һөнәри белеме һәм вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле күнекмәләре) тикшерү.

4.10. Конкурс барышында кулланыла торган бәяләү методлары турында мәгълүматның дәгъва белдерүчеләр өчен үтемле булуын арттыру, шулай ук кандидатка үзлектән әзерләнүгә һәм профессиональ дәрәҗәне арттыруга мотивацияләү максатларында, ул үзенең профессиональ дәрәҗәсен мөстәкыйль бәяләү өчен конкурс кысаларыннан тыш беренчел квалификация тестын (алга таба – беренчел тест) узарга мөмкин, бу хакта конкурс турындагы игъланда күрсәтелә.

Кандидат тарафыннан беренчел тестны узу нәтиҗәләре конкурс комиссиясе тарафыннан игътибарга алына алмый һәм конкурста катнашу өчен аннан документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

4.11. Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия

Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында Министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында хәбәр аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән зат әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.12. Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата куелган квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидатның булуы конкурсның беренче этабын тәгалләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаса яки вазыйфага квалификация таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булса, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка конкурс комиссиясенең карары буенча конкурс комиссиясенең таләп ителгән кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.13. Конкурсның беренче этабының нәтиҗәсе булып билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста алга таба катнашу өчен киңәш ителгән кандидатларның конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан расланган исемлеге тора.

4.14. Конкурсның икенче этабын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турындагы карар граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелгәннән соң, шулай ук, зарурлык булу очрагында, дәүләт серен яисә закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгәннән соң, министр тарафыннан кабул ителә.

4.15. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланган көннән соңгы 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча уздырыла, ә дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләр белән эш итүгә рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта конкурсның икенче этабын уздыру вакыты Министр тарафыннан билгеләнә.

Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык сайтында һәм «Интернет» челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – Дәүләт хезмәте порталы) аның уздырылу датасы, урыны һәм вакыты хакында мәгълүмат урнаштыра һәм

кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә.

4.16. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

«Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Кадрларның бердәм мәгълүмат системасы) кандидатлар турында мәгълүмат кертелә;

кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карары кабул ителә;

нәтиҗәләрне Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында рәсмиләштерү;

конкурс нәтиҗәләрен Министрлык сайтында һәм дәүләт хезмәте порталында бастырып чыгару.

4.17. Конкурс уздырылганда конкурс комиссиясе кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен алар тарафыннан тапшырылган белеме, граждан хезмәтен яки бүтән дәүләт граждан хезмәтен үтүе, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлар нигезендә, шулай ук тест уздыру һәм кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган методларны файдаланып, бүтән конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән тест уздыру, структур бүлекчә эшчәнлеге юнәлеше буенча кандидат тарафыннан документ проектын әзерләү һәм кандидатлар Министрлыкта аны биләү өчен дәгъва белдергән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә шәхси әңгәмә уздыру юлы белән бәяли.

Кандидат конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм конкурс комиссиясе утырышын үткәргәндә министр карары нигезендә видеога һәм (яки) аудиога яздыру эше яки тиешле конкурс процедураларын уздыруның стенограммасы алып барылырга мөмкин.

4.18. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) буенча кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар өчен тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган Тест уздыру методикасына

туры китереп гамәлгә ашырыла.

Тест уздыруны оештыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Министрлыктан Кадрларның бердәм мәгълүмат системасына килгән заявкалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тест уздыру өчен заявка Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында конкурс комиссиясе утырышына кадәр кимендә ике атна калгач формалаштырыла.

Тест нәтиҗәләре Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында чагылдырыла. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс бюллетенендә тест үткәрү нәтиҗәсен 10 баллы системага күчерү юлы белән күрсәтә.

4.19. 6 нчы кушымтада күрсәтелгән кандидатлар тарафыннан документ проектын әзерләү аның вазыйфаи регламентта билгеләнгән һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле вазыйфаи бурычларның турыдан-туры үтәлүе өчен кирәкле белемнәрен һәм күнекмәләрен гамәлдә бәяләү мөмкинлеген бирә.

Кандидатка гражданин мөрәҗәгатенә җавап проектын, норматив хокукый акт проектын (теркәлә торган аңлатма язуы белән бергә) яки әзерләнеше граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) вазыйфаи бурычлары исәбенә керә торган башка төрле документны әзерләргә тәкъдим ителә. Әлеге максатларда кандидатка эш башкару буенча күрсәтмәләр һәм документ проектын тиешле рәвештә әзерләү өчен кирәкле бүтән документлар бирелә.

Әзерләнгән документ проектын бәяләү граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздырыла торган Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан яисә кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан уздырылырга мөмкин. Шул ук вакытта объектив бәяләү үткәрү максатларында әзерләнгән документ проектының аноним булуы тәэмин ителә.

Актыккы билге түбәндәге критерияләр буенча куела:

рәсмиләштерүнең билгеләнгән таләпләренә туры килүе;

мәсьәләнең асылын аңлау, кандидатның документ проектын эшләү өчен нигез булып хезмәт иткән төп фактларны һәм проблемаларны ачыклавы;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы нормаларын дөрес куллануны исәпкә алып, документ проектын эшләү өчен нигез булып хезмәт иткән проблемаларны хәл итү юлларын чагылдыруы;

документ проектын эшләү өчен нигез булып хезмәт иткән проблемаларны хәл итү юлларының нигезләнгән булуы;

аналитик сәләтләре, мантыйкый фикерләве;

хокукый һәм лингвистик грамоталылыгы.

Документ проекты өчен максималь бәя – 10 балл, минималь – 0 балл.

4.20. Конкурс комиссиясе әгъзалары анын утырышы башланырга кимендә өч эш көне калганчы кандидат тарафыннан үтәлгән конкурс биремнәре материаллары белән танышырга тиеш. Күрсәтелгән материалларның исемлеге конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә.

4.21. Әлеге Нигезләмәнең 4.12-4.13 пунктларында күрсәтелгән конкурс процедураларын узган кандидатлар белән шәхси әңгәмә конкурс комиссия әгъзалары тарафыннан уздырыла.

Шәхси әңгәмә уздыру кысаларында кандидатның профессиональ дәрәҗәсен бәяләүгә юнәлдерелгән сораулар бирелә.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына бирелә торган җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын граждан хезмәте вазыйфасына һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләренә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләргә таянып бәяли.

Конкурс комиссиясе утырышы барышында кандидат белән шәхси әңгәмә уздыру мәҗбүри булып тора.

Шәхси әңгәмә уздырганда максималь билге – ун балл, минималь – 0.

Кандидат белән шәхси әңгәмә тәмамланганнан соң конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы 6 нчы кушымтага туры китерелгән формада төзелә торган конкурс бюллетененә, кирәк булганда конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кабул ителгән карарны нигезләүче кыскача дәлилләмә белән, кандидатны бәяләү нәтиҗәсен терки.

4.22. Кандидат белән конкурс комиссиясе тарафыннан кара-каршы шәхси әңгәмә уздырмыйча конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карарын кабул итү рөхсәт ителми.

4.23. Кандидатның актыккы баллы итеп барлык конкурс биремнәре нәтиҗәсендә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган баллар суммасы буларак билгеләнә.

4.24. Кандидатларның ахыргы балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре аларның йомгаклау балларын кимеү тәртибендә кандидатлар рейтингын төзи.

4.25. Конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары конкурсның икенче этап нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.26. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене (кадрлар резервына кертү өчен кандидатны (кандидатларны)) билгеләү турында конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. «Хуплыйм» тавышларын иң күп җыйган кандидат конкурсның җиңүчесе булып таныла.

4.27. Конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы

вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.28. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында Министрлык боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Кадрлар резервына конкурс комиссиясе тарафыннан тупланган балларының гомуми суммасы максималь баллның 50 процентыннан азрак булган кандидатлар арасыннан да кандидатлар тәкъдим ителергә мөмкин.

Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен, кандидатның ризалыгы белән, аны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында Министрлык боерыгы чыгарыла.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү, Министрлык боерыгы күчермәсен граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп, Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.29. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.30. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң җиде көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Шушы ук чорда конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Министрлык сайтында һәм «Интернет» челтәренең күрсәтелгән мәгълүмат системасында да урнаштырыла.

4.31. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларга язмача гаризалары нигезендә конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.

4.32. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән түләнә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

башлана: ____________ сәг.
тәмамлана: __________ сәг.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе «___»_________ 20___ ел, № ______

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының конкурс комиссиясе утырышында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен конкурс аша сайлап алу уздырылды

_______________________________________________

(вазыйфа атамасы, структур бүлекчә (вазыйфалар төркеме) атамасы)

Утырышта _____ конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

Комиссия рәисе: ______________________
(ФИА)

Комиссия рәисе урынбасары: ______________________
(ФИА)

Комиссия секретаре: ______________________
(ФИА)

Комиссия әгъзалары: ______________________
(ФИА)

**КӨН ТӘРТИБЕ**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурсның икенче этабын уздыру

_______________________________________________

(дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары төркеменең атамасы)

Татарстан Республикасы _______________________________________

(структур бүлекчә, булган очракта)

**ТЫҢЛАДЫЛАР:**

______________________________________________________________________

(чыгыш ясаган комиссия әгъзаларының һәм кандидатларның мәгълүматлары күрсәтелә)

**КАРАР КАБУЛ ИТЕЛДЕ:** ______________________________________

(конкурска йомгак ясау турында карар кабул итә)

**Кандидатларны рейтинг буенча бәяләү нәтиҗәләре:**

| №№ т/с | Кандидатның фамилиясе һәм инициаллары | Ахыргы балл | Рейтингтагы урыны (кимү тәртибендә) |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

**Тавыш бирү нәтиҗәләре:**

| №№ т/с | Кандидатның фамилиясе һәм инициаллары | Тавышлар саны | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «хуплый» | «каршы» | «тавыш бирүдән тыела» |
| 3. | | | | |
| 4. | | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәсендә______________________________________________

(кандидатның фамилиясе һәм инициаллары)

тавыш бирүдә катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларыннан иң күп тавыш туплады.

____________________________________ конкурста җиңүче дип танырга

(кандидатның фамилиясе һәм инициаллары)

Министрлыкның кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим итәргә _________

______________________________________________________________________

(кандидат(лар)ның фамилиясе һәм инициаллары)

Конкурс комиссиясе рәисе ______________ ______________________

(имза) (тулы имза)

Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары ______________ ______________________

(имза) (тулы имза)

Конкурс комиссиясе секретаре ______________ ______________________

(имза) (тулы имза)

Конкурс комиссиясе әгъзалары: ______________ ______________________

(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына кертү) буенча кандидатларга карата таләпләр

1. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән, Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфаларын) биләү өчен кирәкле таләпләргә җавап бирә торган, 18 яшенә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белә торган Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (алга таба – граждан хезмәте) биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашу хокукына ия.

Граждан хезмәткәре Министрлыктагы вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста, ул үткәрелгән чорда нинди вазыйфаны биләвенә бәйсез рәвештә, гомуми нигезләрдә катнашырга хокуклы.

2. Гражданин граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләр нигезендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашуга кертелми.

3. Граждан хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте яки белгечлек буенча эш стажына карата законнарда билгеләнгән һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләренә, шулай ук Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаларны үтәү өченк ирәкле, Министр боерыгы белән расланган профессиональ белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы
вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына
кертүгә) конкурс уздыру турында
нигезләмәгә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге

1. Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры исеменә шәхси гариза (Исемлеккә кушымта).

2. Кандидатның шәхесен таныклый торган документ күчермәсе (паспорт, хәрби билет, шәхес таныклыгы).

3. Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган рәвештәге, тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосы белән.

4. Белеме турында һәм квалификациясе турында документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификациясен күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе.

5. Хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш).

6. Хосусый (шәхси) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ күчермәсе.

7. Физик затны салым органында исәпкә алу турында таныклык күчермәсе.

8. Медицина оешмасының дәүләт хезмәтенә керү өчен комачаулый торган авыру булуы (булмавы) турында бәяләмәсе (№ 001-ГС/у рәвешендә).

9. 2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы Федераль законда, бүтән федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәнең Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү буенча кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлегенә кушымта

Татарстан Республикасы төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрына

______________________________________
(министрның фамилиясе, инициаллары)

______________________________________
(фамилия, инициаллар)

______________________________________
яши торган адрес: ________________
______________________________________
тел. __________________________________
(эш, өй, кесә, e-mail)

гариза

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашуга кертүегез турында үтенәм: ____________________________
(вазыйфа, вазыйфалар төркеме атамасы)

________________________________________________________________________.
(структур бүлекчә аталышы)

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә белән, шулай ук вакантлый вазыйфага карата билгеләнгән торган квалификация таләпләре белән таныштырылдым.

Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга карата рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасы үткәрелү белән килешәм.

Конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында e-mail яки күрсәтелгән кесә телефоны номерына СМС-хәбәр җибәрү ярдәмендә хәбәр алуга ризамын.

Гаризага терким: (теркәлә торган документларны санап чыгарга).

____________ ______________________ ____________________
(дата) (имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 4 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары

### 1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте культурасына туры килүе

1.1. Һөнәри максатчанлыгы

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һөнәрдә шәхси потенциал үстерүгә омтылуы, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәттә үсүне күздә тотуы.

1.2. Гражданлык позициясе

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итүе, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен саклау принципларын үтәве.

1.3. Һөнәри позициядәге активлыгы

Куелган мәсьәләләрне хәл иткәндә инициатива күрсәтергә омтылуы; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен хәлдән килгәнчә тырышлык күрсәтергә әзер булуы, физик һәм эмоциональ басым шартларында нәтиҗәле эшгамәл кылуга (стрессларга каршы торуга) сәләтле булуы.

1.4. Үз-үзен үстерүгә әзер булуы

Үз белемнәрен, осталыкларын һәм күнекмәләрен даими камилләштерергә, карашларын киңәйтергә, катнаш һөнәр өлкәләрендә белемнәр һәм тәҗрибә алырга омтылуы.

### 2. Граждан хезмәткәренең һөнәри вәкаләтлелеге

2.1. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә һөнәри белем дәрәҗәсе, юнәлеше һәм сыйфаты.

2.2. Һөнәри тәҗрибәсе

Тиешле һөнәр өлкәсендәге эшчәнлек итү дәвамлылыгы һәм үзенчәлекләре;
һөнәри эшчәнлектә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүе;
карьера үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәре, осталыклары һәм күнекмәләре

Тиешле өлкәдә вазыйфа бурычларын нәтиҗәле башкару мөмкинлеген бирә

торган һөнәри белемнәре дәрәҗәсе;

һөнәри эшчәнлекне регламентлаучы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын белү;

заманча профессиональ технологияләр белән эш итә белүе.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләре

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыра торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютер белүе, гомуми грамоталылыгы, чит телләр белүе һ. б.).

## 3. Граждан хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитикага бәйле сәләтләре

Мәгълүматларны анализлау һәм структуралаштыруны таләп итә торган катлаулы мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген бирә торган системалы һәм сыгылмалы фикерләү дәрәҗәсе;

яңа, стандарт булмаган чишелешләр таба белү сәләте.

3.2. Нәтиҗәле коммуникацияләү күнекмәләре

Эшлекле сөйләм этикасын саклавы;

үз фикерен дәлилләп яклау һәм оппонентларны ышандыру сәләте;

эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләренә ия булуы.

3.3. Җаваплылыгы

Карарларны кабул итүдә нигезле һәм мөстәкыйль эш итүе;

нәтиҗәгә ирешүдә үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булуы.

3.4. Оештыруга бәйле сәләтләре

Үз эшчәнлеген һәм үзенә буйсынып эшләүчеләр эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, вазыйфаларны, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлеп бирү хисабына нәтиҗәләргә ирешә белүе.

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт
граждан хезмәтенең вакантлы
вазыйфасын биләүгә (кадрлар
резервына кертүгә) конкурс уздыру
турында нигезләмәгә 5 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында вакантлы вазыйфаларны биләү (кадрлар резервына кертү) буенча конкурслар үткәргәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурста катнашучыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методлары

| Вазыйфаларның категорияләре | Вазыйфалар төркеме | Төп вазыйфаи бурычлар | Бәяләү методлары |
|---|---|---|---|
| Җитәкчеләр | төп; әйдәп баручы | Министрлыкның, аның структур бүлекчәсенең эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру (максатларын, бурычларын, эшчәнлек юнәлешләрен билгеләү), буйсынудагы затларның хезмәт вакытын оештыру, буйсынудагы затлар арасында бурычларны бүлү, нәтиҗәле коммуникация системасы, шулай ук уңайлы психологик климат булдыру, хезмәткәрләрнең һөнәри эшчәнлеген контрольдә тоту | тест уздыру; шәхси әңгәмә уздыру; Документ проектын әзерләү |
| Белгечләр | әйдәп баручы; өлкән | Министрлык тарафыннан билгеләнгән бурычларны һәм функцияләрне үтәүне профессиональ тәэмин итү буенча мөстәкыйль эшчәнлек | тест уздыру; Шәхси әңгәмә уздыру |
| Тәэмин итүче белгечләр | өлкән | Министрлек эшчәнлеген оештыру, мәгълүмат, документацион, финанс-икътисадый, хуҗалык һәм башка төрле тәэмин итүне башкару | тест уздыру; Шәхси әңгәмә уздыру |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 6 нчы кушымта

## Конкурс бюллетене

«__» ___________________ 20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

_______________________________________________________________
(аны биләү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфаның тулысынча аталышы, яки

_______________________________________________________________
яки кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган вазыйфалар төркеме атамасы)

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Конкурс процедурасының аталышы/ баллар | | | | Куелган баллга кыскача нигезләү (кирәк булганда) |
|---|---|---|---|---|---|
| | тест уздыру | документ проекты* | шәхси әңгәмә* | Җәмгысе | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

* Максималь балл – 10, минималь балл – 0.

____________________________________________ ____________________________

(конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имзасы)».